ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

22.02.2023 ел — № 10

с. Соболевсое

«Соболевский башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» һәм «Чулпаниха башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү учреждениесен бетерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышы үткәрү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Югары Ослан районы, Соболевский авылы, Яр буе урамы, 53 нче йорт адресы буенча урнашкан «Соболевский башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесен бетерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышын үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыелышын 2023 елның 7 мартында иртәнге 10 сәгатьтә Соболевский авылы мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Югары Ослан районы, Соболевский авылы, Яр буе урамы, 30 йорт.

3. ТР, Югары Ослан районы, Чулпаниха авылы, Үзәк урамы, 80 нче йорт адресы буенча урнашкан «Чулпаниха башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль мәгариф учреждениесен бетерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышын үткәрүне билгеләргә.

4. Гражданнар җыелышын 2023 елның 7 мартында 11 сәгатьтә Чулпаниха кибетендә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Югары Ослан районы, Чулпаниха авылы, Үзәк урам, 6а йорт.

5. Әлеге карарны Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова